| КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ |
|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 6 июль

г.Казань

№ 555

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты «Беренче бала туугa (уллыкка алынуга) бәйле рәвештә, айлык түләүне билгеләү һәм гамәлгә ашыру буенча тапшырылган Россия Федерациясе вәкаләтләрен тормышка ашыру өчен Татарстан Республикасы бюджетына федераль бюджеттан субвенцияләр тоту кагыйдәләрен раслау турында» 2018 ел, 15 март, 154 нче карары белән расланган Беренче бала туугa (уллыкка алынуга) бәйле рәвештә, айлык түләүне билгеләү һәм гамәлгә ашыру буенча тапшырылган Россия Федерациясе вәкаләтләрен тормышка ашыру өчен Татарстан Республикасы бюджетына федераль бюджеттан субвенцияләр тоту кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты «Беренче бала туугa (уллыкка алынуга) бәйле рәвештә, айлык түләүне билгеләү һәм гамәлгә ашыру буенча тапшырылган Россия Федерациясе вәкаләтләрен тормышка ашыру өчен Татарстан Республикасы бюджетына федераль бюджеттан субвенцияләр тоту кагыйдәләрен раслау турында» 2018 ел, 15 март, 154 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 ел, 2 июль, 535 нче; 2018 ел, 22 сентябрь, 839 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып)

расланган Беренче бала туугa (уллыкка алынуга) бәйле рәвештә, айлык түләүне билгеләү һәм гамәлгә ашыру буенча тапшырылган Россия Федерациясе вәкаләтләрен тормышка ашыру өчен Татарстан Республикасы бюджетына федераль бюджеттан субвенцияләр тоту кагыйдәләренә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

7 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7. Субвенция исәбеннән субвенция күләменең 1,5 проценты чикләрендә, Россия Федерациясенең тапшырылган вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга бәйле рәвештә, Министрлык һәм Үзәк эшчәнлеген тәэмин итүгә бәйле чыгымнарны компенсацияләү чыгымнары гамәлгә ашырылырга мөмкин.»;

8 нче пунктка түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«Федераль хезмәт һәм халыкны эш белән тәэмин итү хезмәтенә:

ай саен, хисап аеннан соң килүче айның 10 ысыннан да соңга калмыйча, – Федераль хезмәт һәм халыкны эш белән тәэмин итү хезмәте тарафыннан билгеләнгән форма буенча һәм ысул белән (шул исәптән электрон рәвештә) айлык түләү алуның нигезләрен күрсәтеп, айлык түләү алучылар реестрын.».

2. Бу карарның 1 нче пунктындагы икенче һәм өченче абзацлар 2019 елның 8 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры
вазыйфаларын башкаручы Р.К.Нигъмәтуллин